РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
ЧЕРКИ-КИЛЬДУРАЗСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

РЕШЕНИЕ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КИЛДУРАЗ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

КАРАР

22.06.2021 № 22-4

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Килдураз авыл җирлегендә муниципаль
хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр
кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә һәм муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Килдураз авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлеге Советының 2019 елның 27 февралендәге 68-1 номерлы (2020 елның 12 февралендәге 87-1 номерлы, 2020 елның 20 октябрендәге 4-2 номерлы, 23 ноябрендәге 2020 елның 6-1 номерлы, 22 декабрендәге 2020 елның 9-1 номерлы карар редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Килдураз авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 16 бүлек:

16.3 пунктының 7 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «7) Россия Федерациясенең халыкара килешүендә башкасы каралмаган булса, чит ил гражданлыгы (подданлыгы) яисә яшәүгә яисә чит ил дәүләте территориясендә гражданның даими яшәү хокукынраслый торган башка документ булу;»;

1.2. 22 бүлек:

22.1 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22.1. Россия Федерациясе Хезмәт Кодексында каралган хезмәт килешүен өзү өчен нигезләрдән тыш, муниципаль хезмәткәр белән хезмәт килешүе яллаучы (эш бирүче) вәкиле инициативасы буенча да түбәндәге очракларда өзелергә мөмкин:

1) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән иң чик яшькә җитү;;

2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 13, 14.1 һәм 15 статьяларында билгеләнгән муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәү;

3 )дисквалификация рәвешендә административ җәза куллану».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы
Килдураз авыл җирлеге башлыгы З.З. Әхәтов